| Совет Старо-Имянского сельского поселения Сармановского муниципального района Республики Татарстан | | Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Имән авыл җирлеге Советы |
|---|---|---|

| РЕШЕНИЕ<br>05 марта 2019 года | с.Старый Имян | КАРАР<br>№117 |
|---|---|---|

**Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге Советының аерым карарлары үз көчен югалтуын тану турында**

2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы «муниципаль вазыйфа яисә контракт буенча авыл җирлеге башлыгы вазыйфаларын яисә контракт буенча авыл җирлеге башлыгы вазыйфасын биләүгә дәгъва итүче гражданнарның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру тәртибе хакында» Татарстан Республикасы законы кабул ителүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Иске Имән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы "Иске Имән авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Иске Имән авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Иске Имән авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру турындагы нигезләмәне раслау хакында»" 2014 ел, 07 ноябрь, 19 нчы карары һәм “Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Иске Имән авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Иске Имән авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, милек һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру турында Нигезләмәне раслау хакында» 2014 ел, 07 ноябрь, 18 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Иске Имән авыл җирлеге Советы рәисе: Р.А.Исламова